

Мордовиядән алданган пенсионер хатынга 800 мен сум акча кайтарылачак. Бу хакта Мордовия Республикасы прокуратурасында хәбәр иттеләр.
Россия Тикшерv комитеты ин-валиднын морәжәгатеннән сон Атюрьево районы прокуратурасы тикшерv vткәрә. Кvзәтчеләр ачыклаганча, 2025 елнын сентябрендә хатын-кыз мошенникларга зур сумма кvчергән.       Бу факт буенча тикшерv органнары РФ Жинаять кодексынын 159 маддәсенен 3 олеше буенча мошенниклык турында жинаять эше кузгаткан. Тикшерv барышында акча кергән счетнын хужасын ачыклау момкин була. Ул Красноярск кешесе булып чыккан. Акчаларны кире кайтару очен, прокуратура нигезсез баю суммасы буларак 800 мен сум тvләтv турындагы дәгъва белән судка морәжәгать иткән. Суд таләпләрне канәгатьләндергән.
Кvптән тvгел Ардатово районы прокуратурасы мошенниклар тарафыннан алданган пенсионер кызны яклаган: суд Томск олкәсеннән дропперны процентлар белән бергә 125 мен сум кайтарырга мәжбvр иткән. Тагы бер очрак. Мордовиядә Саратовтан телефон мошенникларынын 21 яшьлек курьеры сак астына алынган.
РМ буенча Эчке эшләр министр лыгы хәбәр иткәнчә, ул жирле хатын-кыздан кvчемсез милек залогы белән кредитка алынган 2 миллион сум урлауда шикләнелә. Полициягә Саранскида яшәvче 33 яшьлек хатын морәжәгать иткән. Традицион схема буенча ана ФСБ исеменнән шалтыраттылар һәм анын счетыннан акчаны Украинага ярдәмгә кvчерvләрен әйтәләр. Жаваплылыктан куркып, хатын-кыз әнгәмәдәшләренен кvрсәтмәләрен vтәгән - кvчемсез милек залогына 6,5 миллион сумга рәсмиләштергән. 28 майда ул 4,5 миллионны акчага әйләндергән һәм аларны билгесез кешегә тапшырган. Хәзер аны полиция эзли. 3 июньдә Корбан банкта калган 2 миллионны салдырган, аларны шулай ук анын йортына килгән яшь кешегә тапшырган, алар очрашу вакытында «Валюта» дигән кодлы сvз белән алмашкан. Икенче курьер эзенә хокук сакчылары тошкән, алдакчылар хәрәкәт иткән автомобильне тапканнар. Егетне, 17 яшьлек дусты белән бергә, Саратовта тоткарлыйлар. Дусты тоткарланучыны жинаятьчел хезмәт хакына котырткан.
- Яшvсмер кvп-тән тvгел Липецк олкәсеннән кайтканын хәбәр иткән, анда шул рәвешле жирле хатын-кыздан акча алган һәм дустына остә-мә акча эшләv момкинлегеннән файдаланырга тәкъ-дим иткән. Тегесе ризалаша, - дип сойләгәннәр Эчке эшләр министрлыгында.
Яшьләр 3 июньдә Саранскига таксида киләләр һәм 21 яшьлек шикләнелvче аферистлар тарафыннан алданган хатын-кыздан 2 миллион алганнар. Яшь кешеләр акчаны кураторга кvчерергә олгер-мәгәннәр. Калган сумманы алар сарыф иткәннәр. Егерме бер яшьлек шикләнелvче Мордовиягә китере-лә, ә анын 17 яшьлек иптәше-Липецк олкәсенә, анда ана карата жинаять эше кузгатылган.
Исегезгә тошерәбез, Мордовиядә мошенниклар курьеры полициягә урланган миллион алып килгән. Акчаны карчыкка кире кайтарганнар, ә егет карчыктан гафу vтенгән.
Сак булыгыз, алдакчылар тик тормый – мошенниклык схемаларын янарта баралар.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**